ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел. № 32/11

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенә, 2017 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 463-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11, 2019 елның 25 февралендәге 30/6 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 39, 40 пунктчалар белән тулыландырырга:

«39) кар өемнәре – карны җыештыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән, киңлеге 1,5 метрдан артмаган кар өемнәре;

40) штендер – бер яки ике өслеге булган мобиль конструкцияле тышкы мәгълүмат һәм реклама чарасы.»;

2) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Муниципаль берәмлекнең гомуми кулланудагы территорияләрендә түбәндәгеләр тыела:

1) стационар булмаган сәүдә объектларын, шулай ук ял итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү объектлары (аттракционнар, кабартылган

батутлар, велосипедлар, роликлар прокаты, халыкның ялын һәм күңел ачуын оештыру өчен кулланыла торган башка шундый объектларны) билгеләнгән тәртипне бозып урнаштыру;

2) яшел утыртмаларда (агачларда, куаклыкларда), су торбаларында, урамдагы коймаларда, асфальт һәм плитәләрдә, башка каралмаган урыннарда реклама һәм мәгълүмат материаллары урнаштыру;

3) махсус билгеләнгән урыннардан тыш башка җирдә автотранспорт чараларын юу һәм чистарту;

4) җир эшләрен башкаруга рөхсәт язуы (ордер) булмыйча, җир эшләрен башкару;

5) газоннар, тротуарлар, урамнар, мәйданнар, ишегалды территорияләре, парклар, скверлар һәм башка җәмәгать урыннарында тәмәке төпчекләре, кәгазь, чүп ташлау;

6) бакча диваннарының, эскәмияләренең артына утыру, урналарны, урамны яктыртучы фонарьларны, башка кече архитектура формаларын пычрату, аларга зыян салу яки вату;

7) себерелгән чүпне һәм көнкүреш калдыкларын кое капкачлары, яңгыр сулары канализациясенең су агып төшә торган рәшәткәләре өстенә, улак һәм кюветларга ташлау;

8) махсус билгеләнмәгән урыннарда урам сәүдәсе оештыру;

9) фасадларны рөхсәтсез үзгәртү, билгеләнмәген урыннарда барлык типтагы гаражларны урнаштыру, тышкы мәгълүмат чараларын, кече архитектура формаларын урнаштыру;

10) яшел утыртмаларны сындыру, бозу, юк итү, кәүсәләрне рөхсәтсез кисү, агачларга кадак кагу, гамаклар һәм таганнар, кер баулары элү;

11) газоннарга зыян китерү һәм аларны юк итү;

12) транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштырыру;

13) инженерлык-техник тәэмин итү челтәрен җир асты вариантында һәм проект документларыннан башка төзү;

14) бу максатлар өчен билгеләнмәгән җир участокларында транспорт чаралары кую урыннарын җиһазландыру;

15) штендерлар урнаштыру.»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 36.1, 36.2 пунктларын өстәргә:

«36.1. Каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) булдыру Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты белән килешү нигезендә башкарыла.

36.2. Яр Чаллы шәһәре территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю урыннары (мәйданчыклары) реестры һәм схемасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан кәгазьдә һәм электрон рәвештә алып барыла һәм Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.»;

4) 120 пунктның 6 пунктчасы көчен югалткан дип танырга;

5) 184, 185 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«184. Яңа яуган карны өемнәргә өю, автотранспорт, халык хәрәкәтенә комачаулык тудырмау һәм өелгән өемнәрне 24 сәгать эчендә чыгару шарты белән, барлык урамнарда, мәйданнарда, яр буйларында, бульварларда һәм скверларда рөхсәт ителә.

185. Урамның киңлегенә һәм андагы хәрәкәт характерына карап, кар өемнәрен юлның ике ягы буенча яисә берьяклап, җәяүлеләр һәм автомобиль хәрәкәте өчен юл калдырып, тротуар буйлап өяргә кирәк.

6) түбәндәге эчтәлектәге 207.1 пунктын өстәргә:

«207.1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Сосновский балтырганының таралуына юл куймау максатыннан, физик һәм юридик затлар милек хокукындагы җир участокларында һәм якынтирә территорияләрдә әлеге чүп үләненең үстермәскә тиеш.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мә [illegible] ми комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев